# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Бортас авыл җирлегенең Балчыклы авылында**
**2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**19 ноябрь 2025 ел** **№ 5**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Бортас авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Балчыклы авылында гражданнар җыены:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Бортас авыл җирлегенең Балчыклы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле рәвештә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары булган гражданнардан тыш, 2026 елда гражданнарга үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә.
.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
-ТР, Кама Тамагы районы, Олы Бортас авылы, Ленинград ур., 27,
-ТР, Кама Тамагы районы, Балчыклы авылы, Ленин ур., 70,
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Кама Тамагы муниципаль районы
Олы Бортас авыл җирлеге
башлыгы Р. С. Сәгдиев